**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190**

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
СОВЕТЫ карары

2020 елның 29 декабреннән № 4-28

"2021 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының
муниципаль милеген хосусыйлаштыруның
фараз планы (программасы) турында"

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында" 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында Килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милеген хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында /novosheshminsk. tatarstan. ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгы В. М. Козлов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Советының
29. 12.2020 № 4-28
карарына кушымта

2021 елга Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милеген хосусыйлаштыруның
фараз планы (программасы)

1. Гомуми нигезләмәләр

2021 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль милеген хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) (алга таба – прогноз планы) «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2016 елның 28 июнендәге 15-59 номерлы карары белән расланган Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль милкенә ия булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә эшләнде.

2. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

2021 елда түбәндәге муниципаль күчемсез милек хосусыйлаштырылырга тиеш.
2021 елда ачык аукционнарда сату юлы белән хосусыйлаштырылырга тиешле Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнашкан җир һәм мөлкәтләр Исемлеге

| №п/п | Муниципаль милек исеме | Урнашу урыны | Мәйданы, кв. м. | Хосусыйлаштыруның планлаштырылган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| | Административ бина һәм җир кишәрлеге | ТР, Яңа Чишмә районы, Яңа Иванай авылы, Үзәк ур., 24 а | 600,9 | 2021 елның 3 кварталы |
| | Клуб һәм җир кишәрлеге | ТР, Яңа Чишмә районы, Рус Чабаксары авылы, Речная ур., 6 | 214,7 | 2021 елның 2 кварталы |
| | Гараж бинасы һәм җир кишәрлеге | Яңа Чишмә муниципаль районы, Акбүре авылы, Совет ур., 40 | | 2021 елның 4 кварталы |
| 4 | Гараж бинасы һәм җир кишәрлеге | Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Ленин ур., 37 б | | 2021 елның 3 кварталы |
| 5 | Сугым цехы бинасы һәм җир участогы | Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Парковая ур., 7 | | 2021 елның 4 кварталы |
| 6 | Кибет бинасы һәм җир кишәрлеге | Яңа Чишмә муниципаль районы, Кызыл Октябрь авылы, Үзәк ур., 13 Б | | 2021 елның 3 кварталы |